ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

Постановление Карар

22.04.2019 Чистай шәһәре № 208

Планлаштырылган төзелеш
турындагы белдерүдә күрсәтелгән
шәхси торак төзелеше яки бакча өе
объектлары параметрларының тәңгәл
килүе турында белдерү җибәрү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр
кертү турында

Россия Федерациясенең 2003елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 нче номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендә кабул ителгән 1017нче карары белән расланган планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектлары параметрларының тәңгәл килүе турында белдерү җибәрү буенча
буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Регламентның 1.5нче пунктының 2нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

“гариза бирүче –дәүләт хезмәте күрсәтүче органга яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, 27.07. 2010 елда кабул ителгән 210 нчы номерлы Федераль законының 1 нче маддәсенең 2 һәм 3нче өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга яки әлеге маддәнең 5нче пунктында күрсәтелгән оешмага дәүләт хезмәте яки

муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы, шул исәптән әлеге Федераль законның 15.1 нче маддәсе белән билгеләнгән тәртиптә телдән, язмача яки электрон формада белдерелгән сорау белән мөрәҗәгать иткән физик яки юридик зат (дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнарыннан кала) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре”.

1.2 Регламентның 1.5нче пунктының 3нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:
“төзүче – физик яки юридик зат үзенең җир участогында яки башка хокук иясенең (аңа дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен тормышка ашырганда дәүләт власте органы (дәүләт органнары) атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, “Роскосмос” космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарәсе органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законында билгеләнгән очракларда килешү нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыралар) җир участогында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтү, шулай ук инженерлык эзләнүләре, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документациясе әзерләүне тәэмин итүче. Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы”.

1.3 Регламентның 1.5нче пунктының 4нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:
“техник заказчы – юридик зат, ул төзүче вәкаләте буенча һәм төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләре турында, проект документациясе әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтү турында килешүләр төзи, күрсәтелгән эш төрләрен үтәүгә биремнәр әзерли, инженерлык эзләнүләре үтәүчеләргә, проект документациясе әзерләүне һәм капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтүне гамәлгә ашыручыларга эшләрнең күрсәтелгән төрләрен үтәү өчен кирәк булган материалларны һәм документларны бирә, проект документациясен раслый, капталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен кирәк булган документларга имза куя, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон тарафыннан каралган башка функцияләрне башкара (алга таба - техник заказчы функцияләре). Техник заказчы функцияләре инженерлык эзләнүләре, архитектур-төзелеш проектлавы, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтү өлкәсендәге шул рәвешле үзеннән-үзе көйләнә торган оешмалар әгъзасы тарафыннан гына башкарылырга мөмкин, Шәһәр төзелеше кодексының 47 нче маддәсенең 2.1 өлеше белән, 48 нче маддәсенең 4.1 өлеше белән, 52 нче маддәсенең 2.1 һәм 2.2нче өлеше белән, 55.31 нче маддәсенең 5нче һәм 6 нчы өлешләре белән каралган очраклардан кала”.

1.4. Регламентның 2.9нчы пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
“Планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектлары параметрларының тәңгәл килмәве һәм (яки) җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын

урнаштыру мөмкин булмавы турындагы белдерү төзүчегә шул очракларда гына җибәрелә, әгәр:

1) планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектлары параметрлары рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру буенча документациягә яки Шәһәр төзелеше кодексы, планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү керү датасына гамәлдә булган башка федераль законнар тарафыннан билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына булган мәҗбүри таләпләргә тәңгәл килмәсә;

2) планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларын урнаштыру Россия Федерациясенең җир һәм планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү керү датасына гамәлдә булган башка законнары нигезендә билгеләнгән җир участогыннан файдалану төрләре һәм (яки) чикләүләр нигезендә рөхсәт ителми;

3) планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү җир участогына хокукы булмау сәбәпле төзүче булып тормаучы зат тарафыннан бирелгән яисә җибәрелгән;

4) Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 нче маддәсенең 9нчы өлешендә күрсәтелгән срокта Россия Федерациясе субъектының башкарма властеның мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләте булган органнан шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының тышкы күренешен тасвирлауның тарихи җирлекне саклау предметына һәм федераль һәм төбәк билгеләнешендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектур карарлары таләпләренә тәңгәл килмәве турында белдерү кергән”.

1.5. Регламентның 5.1. пунктының 1 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны теркәү срогын бозу, сорау 27.07. 2010 елда кабул ителгән 210 нчы номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән”.

1.6. Регламентның 5.4. нче пунктының 1 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт яки муниципаль хезмәтне үз вакытында һәм дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты нигезендә алу”.

1.7 Регламентның 5.7. пунктның 1 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, гариза бирүчегә акчаны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган булса”.

2. “Шәһәр төзелеше һәм инфраструктура үсеше” МБУнә әлеге карарны ТРның хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов